КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 сентябрь г.Казань № 1073

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактларын, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне һәм концессия килешүләрен бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артып киткән срокка Татарстан Республикасы исеменнән төзү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72, 78 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактларын, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне һәм концессия килешүләрен бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артып киткән срокка Татарстан Республикасы исеменнән төзү турында карарлар кабул итү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә предметы аларны башкару предметы белән бәйле булмаган кара-каршы йөкләмәләрне күздә тоткан бюджет йөкләмәләренең расланган лимитла- рының гамәлдә булу вакытыннан артык вакытка товарлар китерү (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) булган дәүләт контрактларын төзү хакында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 май, 361 нче;

«Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу вакытыннан артып киткән вакытка Татарстан Республикасы исеменнән дәүләт контрактларын төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2018 ел, 25 декабрь, 1217 нче.

3. Бу карарның гамәлдә булуы Татарстан Республикасы концедент булган, 2022 елның 1 гыйнварыннан төзелгән концессия килешүләреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 5 сентябрь, 1073 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактларын, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне һәм концессия килешүләрен бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артып киткән срокка Татарстан Республикасы исеменнән төзү турында карарлар кабул итү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактларын, дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелә торган, гавами партнеры Татарстан Республикасы булган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрне һәм концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелә торган, Татарстан Республикасы концедент булган концессия килешүләрен Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән очракларда бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артып киткән срокка төзү турында карарлар кабул итү процедурасын билгели.

2. Дәүләт заказчылары эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең җитештерү циклы озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артып киткән Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 статьясы нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турындагы карарында каралган акча чикләрендә әлеге карарда каралган срокка төзергә хокуклы.

Татарстан Республикасы концедент булган концессия килешүләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларында каралган акча чикләрендә концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителә торган концессия килешүләрен төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артык срокка төзелергә мөмкин.

3. Эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең җитештерү циклы озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артып киткән Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары, шулай ук Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар кайтартуга дәүләт контрактлары аның

шартларында үтәү предметлары белән бәйле булмаган кара-каршы йөкләмәләр каралган бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артып киткән срокка Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелергә мөмкин.

Мондый дәүләт контрактлары, һәр сатып алу объектына карата түбәндәге мәгълүматны күрсәтеп, мондый сатып алулар объектларын билгеләү шартлары булганда Татарстан Республикасы дәүләт программаларының тиешле чараларын гамәлгә ашыруга каралган чаралар чикләрендә һәм срокка төзелә:

әгәр дәүләт контракты предметы булып товарлар китерү торса:

сатып алу объекты исеме,

сатып алуны гамәлгә ашыру сроклары,

кара-каршы йөкләмә предметы һәм аны үтәү срогы,

еллар буенча бүлеп, кайтартылган товарларга түләү өчен акчаның иң чик күләме;

әгәр дәүләт контракты предметы булып эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү торса:

сатып алу объекты исеме,

эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең планлаштырыла торган нәтиҗәләре,

сатып алуны гамәлгә ашыру сроклары,

еллар буенча бүлеп, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр нәтиҗәләренә түләү өчен акчаның иң чик күләме.

4. Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында башкарыла торган җитештерү циклы срогы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артыграк булган гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларын һәм аларда ясалма корылмаларны карап тоту эшләрен башкаруга дәүләт контрактларын төзегәндә план чорыннан тыш мондый дәүләт контрактлары өчен түләүгә каралган акчаның еллык чик күләме агымдагы финанс елы һәм план чоры чикләрендә гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма корылмаларны ремонтлауга һәм карап тотуга расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының максималь еллык күләменнән арта алмый.

4.1. Татарстан Республикасы гавами партнер булган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү, Татарстан Республикасы концедент булган концессия килешүе дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителә торган дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителә торган концессия килешүләре нигезендә төбәк бюджеты акчасын алучыга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары гамәлдә булу срогыннан артыграк срокка, Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында әлеге программаларның тиешле чараларында каралган срокка һәм чаралар чикләрендә төзелергә мөмкин.

Әлеге пункт нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт программасы

кысаларында төзелә торган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүнең гамәлдә булу вакыты күрсәтелгән программаны гамәлгә ашыру срогыннан артып киткән очракта, мондый дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителә торган, проекты Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән билгеләнгән тәртиптә килештерелгән дәүләти-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә төзелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында әлеге пункт нигезендә төзелә торган концессия килешүенең гамәлдә булу срогы күрсәтелгән программаны гамәлгә ашыру срогыннан артып киткән очракта, мондый концессия килешүе концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителә торган, проекты Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән билгеләнгән тәртиптә килештерелгән концессион килешү төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә төзелергә мөмкин.

5. Башкарыла торган, күрсәтелә торган җитештерү циклы озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогыннан артып китә торган, әлеге Тәртипнең 2 – 4 пунктларында күрсәтелмәгән Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары түбәндәгеләр билгеләнә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында каралган акча чикләрендә һәм срокка төзелергә мөмкин:

эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең планлаштырыла торган нәтиҗәләре;

эшләр, хезмәтләр составы тасвирламасы;

подрядчыларны, башкаручыларны билгеләү өчен кирәкле срокларны исәпкә алып, эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең иң чик срогы;

еллар буенча бүлеп, озак сроклы дәүләт контрактына түләү өчен акчаның иң чик күләме.

6. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен дәүләт контрактын төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы рәвешендә кабул ителә.

Әлеге карарны әзерләү максатларында республика башкарма хакимият органнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 5 декабрь, 563 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентында (алга таба – Регламент) билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын һәм аның аңлатма язуын Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм, кирәк булганда, башка кызыксынучы органнарга килештерүгә җибәрә.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Регламентта билгеләнгән

тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт программаларына туры килү шарты белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын килештерә.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Регламентта билгеләнгән тәртиптә, түбәндәге шартлар үтәлгәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын килештерә:

агымдагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен дәүләт контракты өчен түләүгә каралган акчаның иң чик күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән тиешле чыгым йөкләмәләрен үтәүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләменнән артмаганда;

план чорыннан тыш дәүләт контракты өчен түләүгә каралган акчаның еллык иң чик күләме план чоры чикләрендә (агымдагы финанс елында) әлеге контракт өчен түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең максималь еллык күләменнән артмаганда.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм (яисә) кызыксынучы органнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын килештерүдән баш тарткан очракта, ул әлеге органнар каравына керткән республика башкарма хакимият органына эшләп бетерү өчен кире кайтарыла.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проекты Регламентта билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә.